| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|


| **ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК** |
|---|---|
| 05.02.2021 | № 24-П |

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2019 елның 22 октябрендәге 126-П номерлы «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территориясе чикләрен раслау турында»гы боерыгының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

Мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең расланган проектын әзерләгәндә булмаган, үткәрелгән тарихи-архитектура, шәһәр төзелеше һәм архив тикшеренүләре нәтиҗәләре буенча, «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 3.1 статьясына таянып, **боерам:**

1. «Казан шәһәрендә урнашкан региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен раслау турында» 2019 елның 22 октябрендәге 126-П номерлы Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты боерыгына 1 нче кушымтага, 39 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«**39.** Казан шәһәре, Кави Нәҗми урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Грандотель» кунакханәсе – Свешников йорты», XIX гасырның 1 яртысы, янкорма 1860 ел, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре **картасы (схемасы)**




**Шартлы билгеләр:**

– мәдәни мирас объекты чикләре

– мәдәни мирас объекты территориясе

•1 – мәдәни мирас объекты чикләренең характерлы нокталары

Казан шәһәре, Кави Нәҗми урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Грандотель» кунакханәсе – Свешников йорты», XIX гасырның 1 яртысы, янкорма 1860 ел, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләре **картографик тасвирламасы**

Төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чиге түбәндәгечә уза:

Көньяк-көнбатыш өлеш: Кави Нәҗми урамыннан җир кишәрлегенең ян чиге буйлап (1-8-7-6-9 борылыш нокталары);

Төньяк-көнбатыш өлеш: Кави Нәҗми урамында, кызыл линия буенча, җир кишәрлегенең алгы чиге буйлап (1-2 борылыш нокталары);

Төньяк-көнчыгыш өлеш: Кави Нәҗми урамыннан җир кишәрлегенең ян чиге буйлап (2-3-4-5 нче борылыш нокталары), төзелеш чиге буйлап (9борылыш нокталары 11-10);

Көньяк-көнчыгыш өлеш: җир кишәрлегенең квартал эчендәге өлеше (6-5 нче борылыш нокталары), төзелеш чиге буйлап (10-11 борылыш нокталары).

Казан шәһәре, Кави Нәҗми урамы, 10 нчы йорт адресы буенча урнашкан «Грандотель» кунакханәсе – Свешников йорты», XIX гасырның 1 яртысы, янкорма 1860 ел, төбәк әһәмияттәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **борылыш ноктлары таблицасы**

| Координатларның җирле координаталар системасындагы нокталары (МСК-16) | | |
|---|---|---|
| **№** | **X** | **Y** |
| 1. | 475912.900 | 1305176.390 |
| 2. | 475907.880 | 1305183.050 |
| 3. | 475908.760 | 1305183.710 |
| 4. | 475902.109 | 1305192.480 |
| 5. | 475872.950 | 1305170.690 |
| 6. | 475868.250 | 1305177.120 |
| 7. | 475860.960 | 1305171.581 |
| 8. | 475861.050 | 1305171.460 |
| 9. | 475865.940 | 1305165.260 |
| 10. | 475867.940 | 1305163.150 |
| 11. | 475878.550 | 1305150.550» |

2. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин